ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamaduşh.tatarstan.ru

Постановление Карар

№ 4 31 гыйнвар 2022 ел.

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 2 гыйнварындагы 5 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитеты карарын №7 29.01.2021ел гамәлдән чыгарырга .

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче /А.Я.Ильин/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31 январь 2022 ел, 4 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3203,78 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 834,79 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2926,11 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Җитәкче / А.Я.Ильин /

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31 январь 2022 ел, 4 нче санлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары,
законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 993,95 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2300,80 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 851,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2818,23 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Җитәкче / А.Я.Ильин /